| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** / **КАРАР**

10.03.2023 г. Казань № 14-2/кс-2023

«ГазТеплоАвтоматика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2023 елның 10 мартындагы 7-ПР номерлы утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ГазТеплоАвтоматика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ГазТеплоАвтоматика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.03.2023 № 14-2/кс-2023
карарына кушымта

## Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ГазТеплоАвтоматика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәре белән | | | | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәреннән башка | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «ГазТеплоАвтоматика» ҖЧҖ* | | | | | | | | |
| 1.1 | Алабуга шәһәре кулланучылары | 180,22 | 169,57 | 191,08 | 180,22 | 174,89 | 164,24 | 185,75 | 174,89 |
| 1.2 | Алабуга муниципаль районы Тарловка авылы территориясендәге кулланучылар | 164,83 | 154,18 | 175,69 | 164,83 | 159,50 | 148,85 | 170,36 | 159,50 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф карарларын
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге